Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ СЕНТЯБРЬ * 2021 * КАЗАН

9



Рөстәм ЗАРИПОВ

ТУКАЙ ИСТАНБУЛДА

Истанбулда аны эзләп байтак йөрдем,
Тукай һәйкәле ди торгач, таптым, күрдем:
Постаментка менгезелгән икән сәке,
Сәкедә бер карт утыра, тоткан пәке...

Карт бик боек, күзләренең дымы кипкән,
Ә кулында пәке түгел, каләм икән...
Эшче чүкеч, керәстиян урак тоткан
Илебездән ошбу калып сәлам микән?

Төркиядә сухта булган Мостафа, дип,
Бәгъзе остаручылардан көлгән Шагыйрь,
"Китмибез!" дигән утлы шигыре белән,
Ватанпәрвәрлекне алга сөргән Шагыйрь,

Төркиягә җилә ала тик пар атта,
Йә бөркет булып талпынып, пар канатта...
Ник соң Тукай монда шундый мөшкел хәлдә?
Йортын ишкәч, бомж күк йөрүе мәллә?..

Ошбу һәйкәлдән бит шулар рухы аңкый,
Бу токымның "гаярьлеге" җанны талкый,
Шулар бутый торгач кара белән акны,
Мөшкеллеккә калды татар шулчаклы...

Болар көчәнүе белән, тора-барып
Культурабыз "көлтүрә"гә турыланды...
Төрле төсләрдәге нурлар тонykланып,
һәр төр иҗат бер дулкында сорыланды...

Компьютер төзәткән тавыш – җырчылыкта,
Музыкаль озатылышлар ят кырчынлыкта
Әдәбияттан әдәп һәм мәгънә качты,
Ни өчен? Чөнки пычаму патамышты...

...Минбеләмнәр экраннардан сата гайбәт,
Тукайны да ыргыталар, кайчак чәйнәп, –
Тәмәке пыскыткан, имеш, качмый-посмый,
Мәдрәсәләре һавасын ыслый-ыслый...

Аннан шәхси тормышына җитә чират,
Тирәнгә кереп казына башлый ир-ат...
Онытылмый өстендәге күлмәге дә,
Төннәрен "хезмәт" күрсәткән чүлмәге дә...

Татарның зыялылары сата гайбәт,
Бар да гамьле, бар да ару, бар да әйбәт...
Сөйләм камил, тәти күренәләр тыштан,
Шагыйрь рухын рәнҗетәләр уздырыштан...

...Милләтнең иң моңлы җыры – Кара урман...
Озын-озак сузып-сузып җырлый торган...
Олуг кайгы – чыкканбыз, һай, Төрксойдан,
Шул турыда бау ишәргә була комнан...

Валерий ТАРАСЕНКО



ШОМБАЙ

болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Түләүле парковкалар керткәндә шәһәр хакимияте аларны бары тик Казанның үзәгендә һәм "бөке"ләрдән котылу максаты белән генә булдырылачак дип ышандырган иде. Әмма чиновниклар җиңел акчаның тәмен тойдылар, ахрысы: алар шәһәр читләренә кадәр тарала башлады. Мәсәлән, үзәктән бик ерак урнашкан Короленко урамында да түләүле парковка барлыкка киләчәк. Шулай итеп, кешеләрне нефть итеп файдаланасызмыни инде, хөрмәтле әфәнделәр?

М. ӘБЛИЕВ

КАЗАН

Укучыбызның хаты Шомбай агада зур кызыксыну уятты.

– Болай булса, тиздән бездән үз гәүдәбезне түшәгебездә "парковкалаган" өчен дә акча суыра башлаячаклар, – диде аксакал. **Ярты сәгатькә ятып тору – бушлай, ә озаграк булса – тариф буенча...**

Ринат АБЗАЛОВ

ИГЕННӘР

Башларын иделәр эсседән
Тамчыга сусаган игеннәр.
"И Ходай, бирче бер, бер яңгыр", –
Диделәр кипшергән иреннәр...

Житмәде күкләргә ялвару –
Игеннәр киптеләр... үлделәр...
Ә күктән аз гына астарак
Утырган агайлар көлделәр...

Аларның кулына афәттән
Яңадан алтыннар коелды.
Ә илнең күнеккән тәненә
Тагын бер җәрәхәт уелды...

ҖӘЙГЕ ЭТЮД

...Дыңгырдатып иске тарантасын,
Очкын чагып көпчәк эзеннән,
Күк хуҗасы, болытларны ертып,
Үтеп китте гөмбәз өстеннән.
Эсселектән иза чиккән дөнья
Тирән сулап куйды – купты җил,
Һәм ишелде җиргә шифа булып,
Ут һәм судан торган коктейль!

Виктор ФЁДОРОВ





Николай ВОРОНЦОВ

Койма рецидивистлары

Билгеле булганча, бер елгага ике тапкыр кереп булмый. Бу гыйбарә казанлыларга бик яхшы таныш, чөнки шәһәр суларында бер генә кат чыланып чыгу да катлаулы. Казанның ике зур елга һәм Кабан күле ярында урнашуына карамастан, миллион ярымлы шәһәрдә хәвефсез үз ваннаңда гына коенырга була. Бу гаҗәеп хәлнең ике сәбәбе бар.

Һәр җәйдә республика Роспотребнадзоры пляжлардагы хәлнең санитар таләпләргә туры килүен тикшерә. Нәтиҗәдә, мондый пляжларда ял итеп һәм коенып чыкканнан соң анда төрле паразитлар һәм вируслар эләктерү мөмкинлеге булуы ачыклана. Мәсәлән, быел республикадагы коену урыннарының рәсми рәвештә алтысы гына ачык, һәм аларның берсе дә Казанда түгел.

Сәламәтлекләренә төкереп караган һәм исләре дә китмичә шундый суларда "су чәчрәтеп уйнарга" курыкмаган кешеләр буа буарлык. Нишлисең бит – чиста су ярларына анда да, монда да койма һәм рәшәткәләр куелган, һәм бу мәсьәләне чишү җиңелләрдән түгел.

Километрларга сузылган гомуми файдалану ярларын шәхси пляжлар һәм пирслар белән җиһазланган коттедж хуҗалары яулап алган. Табигать саклау законнарын бозучыларның күбесе дәрәҗәле урын һәм зур акча ияләре, шуңа күрә аларга судан коры чыгу кыен түгел. Мисал өчен, Казан янындагы Боровое Матюшино һәм Чаллыдагы Белоус бистәсен генә алыйк. Бу урыннарда гади коенучыга Идел һәм Кама ярларына барып чыгу җиңел булмаячак. Дөрес, бу затлы урыннарда вакыты-вакыты белән яр хуҗаларына карата өстән-өстән генә тикшерүләр уздырылгалый. Мәсәлән, алты ел элек республика президенты күрсәтмәсе буенча бу эшкә тотынганнар иде, ләкин баштан ук сак кына һәр очрак шәхси рәвештә каралачак, дип белдерделәр. Ә елга ярларына законсыз хуҗа булган өчен чара күрү турында сүз дә бармый. Дәүләт бит торган биналарны алдын-артын карамый җимереп ташлый алмый. Шуңа күрә күп кенә вакыт узуына карамастан, беркемне дә җәзага тарту очраклары булмады.


Тик шулай да елга-яр кагыйдәләрен бозучылар белән көрәш алып барыла, ләкин "балык"ның ваграгы белән. Күптән түгел генә Чаллы янындагы Санар бистәсендә дача торучыларның елгага юлын каплап торган ике метрлы койманы алып ташладылар. Әлмәт районының Сосновка авылында Урман Зәе елгасыннан коймасын тиешле 20 метр урынына 9 метр ераклыкта куйган кагыйдә бозучыны җәзага тарттылар. Ә менә Яшел Үзән районында Идел буенда 4 метрлы дивар корган эшмәкәрнең койманы күчерү турындагы суд карарына исе дә китми. "Яр хуҗасы" моны судның күчерү урынының төгәл координатларын бирмәве белән аңлата.

Гомумән, законсыз куелган койманы законлы рәвештә алып ату иләк белән су ташуга тиң. Әгәр дә суд карары үтәлми икән, пристав кагыйдә бозучы янына бер елдан соң гына килә ала. Аннан соң бюджетта койманы алу өчен акча табарга, тендер уздырырга, подрядчик табарга һәм эш өчен түләргә... һәм бөтен эшне бер ел эчендә башкарырга кирәк — каралган акча киләсе елга күчми. Ә җир хуҗасына яңа койма куярга нәрсә комачаулый? Моның өчен аны бары тик 3–5 мең штрафка тарта алалар, ә аннан соң бөтенесе дә өр-яңадан башлана. Һәм мондый хәйләкәр "койма рецидивистлары" Иделдәге су хәтле.

Суга чыгу проблемасы шундый масштаблар алды ки, илдә хәтта "Ачык яр" дип исемләнгән иҗтимагый хәрәкәт барлыкка килде. Аның хезмәткәрләре "приватизацияләнгән" сусаклагычларның интерактив картасын төзеделәр, һәм ул даими рәвештә яңартылып тора. Кыенлыкларга карамастан, аларның уңышлы тәмләгән эшләре аз түгел, ләкин бу елгадагы тамчы кебек – коймалар бюрократик механизмның хәрәкәтенә караганда тизрәк үсә, ә шома яр хуҗаларының бернәрсәгә дә исе китми. Юри генә Идел яры буенча узып карагыз. Шунда ук сез бетон диварлар һәм чәнечкеле чыбык лабиринтларында адашачаксыз. Ничәмә еллар инде анда адашып йөргән табигать саклау законнары шикелле...

Людмила САФИУЛЛИНА











• • •

Дөньяда көлкеле хәлләр арткан-нан-арта, ә җәзасыз көлү мөмкинчелеге кимегәннән-кими.

• • •

– Минем алмагачларда күбәләк кортлары күбәйде. Мөгаен, алмасыз калырмын.
– Ә син агачка кошлар ияләштер.
– Әйбәт булыр иде дә бит, ләкин ничек?
– Машинаңны алмагач астына куй.

• • •

Адвокатлар тычканнарга караганда да эчкерсезрәк: тычканнар, каракланып, сыр кимерсәләр, адвокатлар законнардагы тишекләр белән тукланалар.

• • •

Ресторанда.
– Кабымлыкка нәрсә китерик сезгә?
– Каймаклы уылган кишер.
– Ныгытып тамак туйдырыр өчен ни кирәк?
– Кишер котлеты.
– Эчәргә нәрсә?
– Кишер согы.
– Десертка?
– Кишер торты.
– Бай яшисез!

• • •

– Сез кайда яшәргә теләр идегез?
– Мин "кайда" түгел, ә "ничек" яшәргә теләр идем.

• • •


Телефоннан күп сөйләшүче хатынына – ире:
– Мин шаккатам, син ничек егерме минутта сөйләшеп бетердең?
– Дөрес номер җыймаганнар...

• • •

Үзара әңгәмәдә.
– Сөйләгез, сез нәрсә эшли беләсез?
– Бернәрсә дә белмим.
– Гафу итегез. Бу урыннар инде буш түгел.

• • •

Бер ханым табиб янында:
– Доктор, берәр киңәш бирмәссез микән: ирем төннәр буе йокы аралаш сөйләнеп ята.
– Сез аңа көндез сөйләргә ирек биреп карагыз.


Максим СМАГИН

Илдар НӘФИЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Алмаз ХӘМЗИН

ТӘҢГӘЛЛЕК...

Кайбер журнал тышлыкларын
Бизи чибәр ханымнар.
Барысы да уңган-булган,
Җитәкчеләр – вуменнар.

Карыйм да аптырап куям:
Әле болар ни кылган?..
Тормышыннан канәгатьлек
Кыяфәтенә кунган.

Тырнаклары төрле лакта,
Бриллиантлар – колакта.
Күреп торам, сукмый болар,
Бармакны да бармакка.

Ник чыкмый журналда, әйтик,
Эшләп алҗып беткәне?..
Мал-туарлар асраганы,
Заводта эш иткәне?

Авыл апасы тир түгә,
Иртәдән кичкә кадәр.
Казын карый, үрдәкләрен,
Тавык-чебеше – йөзәр.

Сыер, бозау, танасы бар,
Мөгериләр абзарда.
Мең мәшәкать – чыда гына,
Вакыт калмый моң-зарга.

90 яшьлек карт әнисен
Тәрбияли һаман да.
Үзен үстергәндәй назы,
Игътибары анага.

Бакчасында бәрәңгесе –
Унбиш сутый диярлек.
Аягыннан ботый төшми,
Йон носкилап киярлек.

Яшелчәләр үстерә ул:
Суган, кыяр, помидор;
Кишер, шалкан һәм кәбестә –
Бакчасы шулай бик зур.

Санап бетерерлек түгел
Мәшәкатьне авылда.
Кая монда тырнак буяу,
Ир дә хәтта – муенда...

Эремчек илтә калага,
Вумен битен майларга;
Сөте китә ваннасына,
Коенырга аңарга.

Инде, ярый, бу ханымнар
Чынлап алга киткәннәр...
Чаманы белмичә артык
Кәпрәйгәннәр – "үскәннәр"...

Арттырышсыз... мәсьәләдә
Барысы да бик төгәл.
Турысын әйтсәм, болар бит –
Секс символга нык тәңгәл!

Александр БРЮХАНОВ

Картина

– Шәп бу! Минем фикер шундый! – диде хакимият башлыгы, картинаны карап чыккач, һәм гадәттәгечә кулын күтәрә башлады.

– Юк, юк, – дип тотып алды аның кулын Сәламәтлек саклау бүлеге мөдире. – Тиресе ниндидер саргылт... артык юан... һәм ятуы да тере булмаган кебек... Мин аңа район хастаханәсендә түләүле диспансеризация үтәргә тәкъдим итәр идем...

– Нишләп тере булмасын?! – дип талпынып куйды полиция башлыгы. – Карап торырга менә дигән... Тик кыяфәте генә әхлак нормаларына туры килеп бетми... Берәр нәрсә белән ябынса иде, ичмасам...

– Ул махсус рәвештә шулай ята – тыңлый һәм исендә калдыра, – дип тавыш бирде игътибарлы ФСБ башлыгы. – Безнең кеше!

– Шәрәлек күләме мине дә борчый, – диде урта яшьләрдәге Район мәгариф бүлеген җитәкләүче ханым. – Яшүсмерләргә нинди үрнәк бирәбез? Монда 18+ билгесе куярга кирәк!

– Монысы инде артык! – дип бүлде аны башлык. – Алар интернеттан әллә ниләр карыйлар...

– Ә аңа яктыртылуы бик ошый, йомшак һәм тигез таралган, энергия саклаучы лампалар файдаланганнар булса кирәк, – диде уйчан караш белән җирле электр челтәре башлыгы.

– Ә картинадагы алтын бүгенге курс буенча ике мең биш йөз алты доллар һәм биш центлык, – диде банк директоры, калькуляторына карап алгач.

– Шундый хатын булганда акча саныйлармыни, – диде уйчан гына башлык, хатынына карап алып.

– Мондый акчам булса, миндә ким булмас идем, – диде башлыкның хатыны, чәчен төзәтеп, һәм банк директорына мәгънәле караш ташлады.

– Ә миңа рамасы бик ошады, – дип аваз салды военком, – безнең оборона кебек нык һәм ышанычлы...


– Димәк, кабул иттек? – дип нәтиҗә ясады башлык, картинадан күзен алмыйча.

Шуның белән район музеенда "Даная" картинасының күчермәсен кабул итү тәмам булды. Картинаны халыкка күрсәтү өчен югары рөхсәт алынды.

Игорь КИЙКО



Александр АЛЁШИН



– Сез әтиемне күрергә теләгән идегез – аның секретарена кабул итүгә язылыгыз!

Абау!

ЮМАРТ БҮЛӘК

21 миллион сум үзләштерүдә гаепләнүче Түбән Камадагы «Ростатнефть» фирмасы директоры Илья Шиалей аның эшен алып баручы судья файдасына... васыять язган. Шундый ысул белән ул җинаять эшен караганда туган "киртәләрне" юкка чыгарырга өметләнгән. Әмма намуслы суд башлыгы юмарт бүләкне кабул итмәгән. Ул моны хәтта законлы варислар да мираска дәгъва белдерә алмыйлар, дип аңлаткан һәм киң күңелле директорны 9 елга колониягә ябып куйган.

КИЯҮ ЯНЫНА ЮЛ


Биектау районындагы Дөбьяз авыл җирлеге Башкарма комитетының элекке җитәкчесенең киявенә карата артык җылы мөнәсәбәттә булуы билгеле булган. Исполком бистә эчендәге юлларны таш белән каплау турында килешенү төзегән. Бу изге эш өчен акча анда яшәүче кешеләрдән җыелган һәм бюджеттан алынган. Ләкин тикшерү нәтиҗәсендә бистәдән читтә урнашкан тагын ике юлны таш белән каплау ачыкланган. Алар икесе дә кияүнеке икән. Нәни хәйләдән 2 миллион сумлык зыян килгән.

ХӘВЕФЛЕ СӘЯХӘТЛӘР

Казанда ЮХИДИ хезмәткәрләре шәһәр, районнарда һәм күрше өлкәләргә йөрүче биш йөзгә якын автобусны тикшергәннәр. Аларның һәр бишенчесендә техник җитешсезлекләр табылган. Мәсәлән, 25 нче автобуста тормоз йә руль төзексез булып чыккан, ләкин алар маршрутка чыгып йөргәннәр. Нәтиҗәдә, 263 йөртүче һәм 29 автопредприятиенең җаваплы хезмәткәре административ базага тартылган.

БАРЫСЫН ДА – ӨЙГӘ

Алабугада мәктәп директорларының берсе үзенә тапшырылган учреждениедә "шәхси-дәүләт партнёрлыгы" оештырган. Ул 150 квадрат метр мәйданны арендага биргән, ә андагы кибетнең мөдирен (үзенең хатынын), мәктәпкә методист итеп урнаштырган. Сатучыларга үз кесәсеннән хезмәт хакы түләмәс өчен, алары да рәсми рәвештә мәгариф оешмасы хезмәткәрләре булып саналганнар. Аның улына да урын табылган – ул, мәктәп җиһазларын файдаланып, күчермәләр ясау үзеге ачып җибәргән. Директорның чиктән ашкан үткенлеге миллион ярым зыян китергән, ә үзенә каршы җинаять эше кузгатылган.










Валерий ТАРАСЕНКО


Валерий ТАРАСЕНКО

Наталья БАХТИНА

Нәсел каһәре

Бу каһәр әтиләре ягыннан бөтен ирләр дучар иде. Барчасы да, бабасының бабасыннан башлап, бары тик хак сүз генә сөйләргә мәҗбүр иде. Бу туры теллеләрне заманасына карап төрлечә атыйлар иде: дөнья болгатучы, хөррият сөюче, халык дошманы, диссидент...

Менә Васяны да бу нәрсә читләтеп узмады. Мәктәптә ул беркайчан да күчереп язмады, һәм сыйныфта берданбер бала буларак, хезмәт дәресләрен калдырмады. Бернинди ярдәмсез, үз көче белән кергән университеттан аны икенче курста куып чыгардылар. Ул имтихан өчен ришвәт төртүдән баш тарткан берданбер студент булып чыкты. Армиядә туры теле өчен чираттан тыш нарядлар Василийга башкаларга караганда ешрак эләгә иде. Ватанга бурычын түләгәч, ул югары белем алды. Юрфак бетергән яшь белгеч полициядә озак эшли алмады. Берничек тә күрсәткечләр өчен гаепсезләргә каршы җинаять эшләре кузгата алмады. Адвокатлык өлкәсендә дә эше пешмәде. Василий кабахәтләрне һәм башкисәрләрне яклауга чын күңеленнән каршы булды. Калганнарыннан акча суырмады, эшнең отышсыз булуы турында алдан ук кисәтеп куйды. Кыскасы, безнең Вася гади сатучы дәрәҗәсенә кадәр төште. Ләкин бер генә кибеттә дә озак тоткарланып тора алмады. Чөнки ул сатып алучыларны автозапчастьларның контрафакт булуы, колбасаның итсез, ә модельле итальян туфлиләрнең күрше йортның подвалында хезмәт сөючән мигрантлар тарафыннан эшләнүе турында кисәтеп торды. Тик аңа да карамастан, Василийны халык ихтирам итә иде. Ул хәтта нindидер сайлауда кандидат булып чыкты. Васяның төп вәгъдәсе бары тик дөреслек сөйләү иде, тик, нишләптер, анда аның көндәше, яманаты чыккан саф карашлы ялганчы җиңеп чыкты...

Тиздән Василий үзе кебек үк намуслы кызга өйләнде. Яши башлады болар. Ләкин яшь хатын Васяның акчасыз тормышы белән танышкач, "Болай яшәргә ярамый!" дигән катгый фикергә килде. Ә нәсел каһәре турында белгәч, аннан котылырга карар кылды. Хатынының киңәше буенча Василий төрле шәхси үсеш һәм матди уңышка ирешү мәктәпләренә йөри башлады. Хатыны аны көненә 3-4 сәгать телевизордан шау-шулы мәгънәсез тапшырулар карарга мәҗбүр итте. Ул шулай итте дә...

Һәм ярдәм итте бит! Хатынының мәшәкатьләре юкка китмәде. Берникадәр вакыттан Василий адвокатлыкка кайтты. Хәзер аның үзәк өзгеч нотыкларыннан судья, сакчылар һәм бөтен зал елый, ә зыян күргән кеше шикләнә башлый: эскәмиядә утыручы бу тыйнак кешеләр аны чынлап та талады микән? Берничә отылган шау-шулы процесстан соң Василийның йөзе телевидениедә күренгәли башлады, ә тормышны әкияткә әйләндерү турындагы вәгъдәләрдән соң тагын каядыр сайланырга җыена...

Күргәнебезчә, теләсә нинди язмышны үзгәртергә һәм яхшыртырга була. Нәсел каһәрләрең читтә торсын...



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Машиналар язмышы – безнең хәләт...

Соңгы вакытта безнең ишегалдына асфальт җәйгәч, машиналар күбәйде. Төн җитү белән сигнализацияләре чырылдый башлый...

– Карак, карак, карак, – дип кычкыра берсе.

– Кайда, кайда? – дип борчыла башлый икенчесе.

– Полиция-я, полиция-я! – дигәндәй караңгы почмактагысы чиный.

– Талыйлар, талыйлар! – дип үкерә өченчесе.

Шулчак кайдадыр:

– Бер йокы бирмисез, – дип мыгырдады искереп беткән "Запорожец".

– Сиңа нәрсә, – диде аңа "Джип", – синең көпчәгең дә калмаган бит инде, урлыйсы нәрсәң юк, шуңа борчылмыйсың.

– Мин кирәген йөрдем инде, хәзер ял итсәм дә ярый. Көпчәкләрем булмаса да, файда китерәм – көндез балалар уйный, төнлә бомжлар йоклый.

Машиналар хихылдап куйды.

– Менә мин бүген бик күп йөрдем, арылды шул, - дип уфылдады иномарка.

– Арырсың да, хуҗаң сине "кызлар" йөртер өчен тота бит. Хатыны икенче машинада йөри. Әнә ерак түгел генә тора аныкы. Кызыл төсле.

Алар сөйләшкән арада яннарына тагын бик тә хәтәр машина килеп туктады. Хуҗасы як-ягына каранды да подъездга кереп китте.

– Менә шулдыр инде синең төшеңә кергән карак, төнлә генә кайта, кеше күрмәгәндә. Кайларда йөридер?..

– Сез минем хуҗаны әйтәсезме? – дип сорады әле генә кайткан машина. – Чут кенә котылдык без бүген. Артыбыздан кудылар. Әле ярый миңа тигезә алмадылар атып. Югыйсә дәваланып ятарга туры килер иде.

– Сез бүген ял итәргә уйлыйсызмы-юкмы? – дип мырылдады янәшәдәге гаражда торган машина.

– Ә-ә, син дә исәнмени? Сиңа рәхәт, гаражыңда посып ятасың, депутат машинасы булгач. Беркем тими, көпчәгеңне дә салдырмый, тәрәзәңне дә ватмый, – дип ябыштылар аңа урамдагы машиналар, яңадан ишегалдында тавыш күтәреп. – Неприкосновенный! С особым статусом!..


– Ярый, җитте сезгә, – диде иске Запорожец. – Озакламый таң ата башлый. Ял итик. Әнә минем клиент килә. Кичәге кебек, бүген хатыны тагын өенә кертмәгән, күрәсең.


Машиналар тынды. Фараларын сүндереп, йокыга талдылар. Ләкин озак та үтмәс, яшенле яңгыр килеп, күк күкрәп, аларны тагын уятыр.

Хәер, монысы башка мәсьәлә...



Виктор ФЁДОРОВ


Анастасия ВАСИЛЬЕВА





Евгений ОБУХОВ

УҢАЙСЫЗ КҮРШЕЛӘР

– Әлү, исәнмесез!

– Тыңлыйм.

– Мин сезне бик шәп ярдәм итәсез икән дип ишеттем?

– Әйе, нәкъ шулай. Теләсә нәрсәне хәл итә алабыз. Проблемагыз нинди, командир?

– Ничек әйтим икән... Котылырга кирәк иде... Уңайсыз күршеләрдән.

– Эшлибез аны. Безнең бәяләрне хәбәр иттеләрме?

– Теләсә нинди акча түлим, ярдәм итегез генә. Изаланып беттем мин алар белән.

– Бик шәп! Акча гына әзерләп куегыз. Эзләре дә калмас кабахәтләрнең.

– Вәт рәхмәт! Эш вакытында йорт хайваннарын фатирдан чыгарып торасымы?

– Кәнишне. Ялгыш зыян китерүебез бар.

– Шаяртасыз... Тик алар миндә бии-к күп. Патроннарыгыз җитәрме соң? һә-һә-һә...

– Ә безгә барыбер, эш эш инде ул. Синең анда, нәрсә, каралар яшиме әллә?

– Нишләп кара? Җиреннәре дияр идем – нимесләр, "прусаклар"...

– Менә сиңа мә! Димәк, нимесләр чабышып йөри?

– Мин сезне аңлый алмыйм әле... Алар кухняда ут яндыру белән чабыша башлыйлар. Суыткыч янында нәрсәдер ашыйлар, ахрысы.

– Вәт оятсызлар, сорамыйча суыткычтан ашыйлармы?! Булды, теңкәгә тиделәр! Адресыңны әйт – хәзер килеп җитәбез. Акчаңны әзерләп куй, бер башка мең бакс.

– Мең доллар? Кыйммммәтрәк түгелме соң? Нишләптер сезнең шаяртуларыгыз миңа барып җитми әле... Мин сезгә тараканнар турында сөйлим бит.

– Һи, командир, ә без нәрсә турында! Без үзләре яши башлап, бөтен туган-тумачасын үзләренә тартучыларны шулай атыйбыз. Курыкма! Нәкъ кирәкле җиргә туры килдең!..

– Чынлапмы?

– Әйе. Безгә эләксәң, ычкына алмассың!



Абау!

ЭТӘРГЕЧ ТИЕННӘР

Костромада автотранспорт колледжы укытучылары 50 тиен һәм 2,5 сум күләмендә премия алганнар. Соңгы елларда алар тиешле этәргеч түләүләрне бөтенләй алмаганнар, һәм бары судка мөрәҗәгать иткәннән соң гына акчалары үз кешеләрен тапкан. Өлкә мәгариф һәм фән департаментында мондый суммаларның берничек тә яхшы хезмәткә этәргеч була алмавын таныган һәм хәзер 5 тән 10 елга кадәр стаж өчен аена 50 тиен түгел, ә 500 сум, ә 20 елдан артык стаж өчен 2,5 мең урынына 2,5 мең түләячәкләрен белдергән.

ҖИНАЯТЬЧЕЛЕК АЛЬТРУИЗМ

Мордовиядә яшәүче Игорь Рогожин авылдашлары өчен игелекле эш башкарырга булган. Дүрт көн эчендә ул урмандагы юлны чистарткан, ә җирле халык моны дәүләттән берничә ел эшләүләрен сораган булган. Хәзер Кадошкино районының өч авылында яшәүчеләр тоткарлыксыз район үзәгенә бара алалар, ә аларга, үз чиратында, янгын сүндерү машиналары һәм ашыгыч ярдәм күрсәтү хезмәтләре килә ала. Әмма ир-атка альтруизм өчен түләргә туры киләчәк – түрәләр аны законсыз рәвештә яшел үсентеләр кисүдә гаепләгән һәм аңа карата җинаять эше кузгаткан.


ИЛАҺИ ХАКИМИЯТЕ

Мари Иле Республикасы Дәүләт җыены депутаты үз сайлаучыларын җитәкчелек алдында баш иярга чакырган. Сернур бистәсендә хезмәт ветераннары белән очрашу барышында ул кешеләрнең һәрвакыт «хакимияткә нәрсә дә булса исбатларга» омтылуларына зарланган. «Хакимияткә каршы берни дә эшләргә ярамый. Яһүдләр әйтүенчә: башлыкны күрденме, нәрсә эшләргә кирәк? Сәҗдә кылырга! Барча мәхлукның тәрбиячесе булып тәңре үзе генә була ала. Аның белән ничек бәхәсләшеп булсын?» – дип өйрәткән үзенең «мәхәллә кешеләрен» халык хезмәтчесе.

КИРӘКЛЕГӘ ӨЙРӘТМӘГӘН

Мәскәү прокуратурасы Казакъстан репетиторы эшен судка җибәргән. 30 яшьлек егетне 13 яшьлек улларын укуда «тарттыру» өчен бер гаилә яллаган. Әмма яшүсмернең башына мәктәп белемнәрен сеңдерү урынына, репетитор малайны әтисеннән акча урларга һәм аның белән бергә Казакъстанга качарга күндергән. Яшүсмер өйдән 3 миллион сум акча алган һәм шулай ук әтисе счетыннан тагын 100 мең сум акча күчергән. Әмма ахыргы пунктка кадәр барып өлгерә алмаганнар, аларны Свердловск өлкәсендә тоткарлаганнар.





Мирзаһит тормышыннан

БУТАУЧЫ

Авылда бер-берсенә охшаган ике урам бар иде: Халык урамы мәктәпкә илтә, ә Зур кеше урамы – район начальнигы йортына. Халыкныкы чокыр-чакырлы һәм пычрак, сулы, Зур Кешенеке – тигез һәм чиста. Беренче урамда кычыткандыр, чүп үләннәредер, ә икенчесендә – төрле-төрле декоратив чәчәкләр.

Беркөнне авылга ком, вакташ һәм асфальт төяп зур машиналар килде.

– Ниһаять безнең урам юлын төзекләндерерләр, – дип, шатлыклары эченә сыймады Халык урамындагыларның, – балалар мәктәпкә пычранмыйча бара алмыйлар иде!

Ләкин техника, Халык урамын үтеп, алга узды. Зур Кеше урамына яңа асфальт җәячәкләр икән. Халыкның ризасызлыгы чиктән ашкан иде, ләкин берәү дә берни эшли алмый шул.

Шуннан соң, ярты еллап вакыт узгач, авылга тикшерүчеләр килде. Авылның кемедер шикаять язып җибәргән һәм бу кәгазь, бөтен кабинетларны үтеп, кирәк кешегә барып җиткән.

Чынлыкта эш болай булган: рәсми кәгазьләрдә Зур Кеше урамы түгел, ә Халык урамы ремонтланган. Әйтүләренә караганда, проектта чәчәк түтәлләре дә, җәяүлеләр өчен асфальт түшәлгән сукмак та ясаласы булган. Кәгазьнең астына Зур Кеше урамында яшәүче әлеге начальникның кулы да бик шәплəп сырланган. Менә шушы буталчык белән бик озак рәтенә төшенә алмыйча азапланды тикшерүчеләр. Начальник шундук хәбәр салган – "кемдер кайдадыр, нәрсәдер бутаган", үзе дә аптыраган, йөдәгән, ничек шулай килеп чыкканына. Шуннан соң тикшерүчеләр авыл халкы белән сөйләшә башлаганнар:

– Сез ничек уйлыйсыз, бәлки, ул чыннан да буталган? Кем белән булмас шундый хәл?

– Әлбәттә, бутаган, – дип җавап биргән Мирзаһит. – Ул һәрвакыт шундый! Мәктәп директоры булганда да ул бөтен укытучыларга йөзәр тәңкә язган, үзенә – ун мең. Бутаган. Ә инде район начальнигы булгач, ялгышып, фермадагы яңа сарай урынына, үзенә ике этажлы йорт җиткереп куйган.

– Аңа чынлап та ялгышлары өстендә эшләргә туры киләчәк, югыйсә тагын әллә ниләр бутап куюы бар, дигән нәтиҗә ясаган булып, тикшерүчеләр ялтырап торган асфальт буйлап начальник йортына таба атлаганнар.

ФУТБОЛКА


Берзаман Мирзаһит хатыны белән сүзгә килгән. Юк кына нәрсә өчен инде нәкъ бала-чагалар кебек үпкәләшкәннәр. Мирзаһит, галошларын киеп, бишмәтен элəктереп, лапастагы эш коралларын рәткә китерергә юнәлгән. Ә хатыны кул астына эләккән чүпрәк алып, мунчадан чиләккә җылымса су салып, җенләнеп идән юарга тотынган. Икенче бүлмәдән боларның шаулашканнарын ишетеп, җиде яшьлек Айнур чыккан. Ул әнисенең тырышып эшләвенә күз салып, сүзен башлаган:

– Әни, әгәр дә без синең белән ачуланышсак, син минем футболканы алып идән юарсыңмы?


Әнисе башта берни аңламаган, аннан соң көлүеннән туктый алмый интеккән. Ул бит, кызуланып, иренең футболкасын алган икән.

– Менә вәт, яшь Мирзаһит үсә, чынлап! – дигән ул иренә, шушы хәлне сөйләп. Үпкәләшүләре шундук онытылган.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Игорь КИЙКО



Лия БОЧКОВА, 1980 ел.

– Курчак түгел бу, гражданин, ә минем кызым... Бакчага урнаштыра алмыйм.


Иван ХАНТИМЕРОВ, 1980 ел.

–Безгә ревизия килә. Ашарга яраклы әйбер пешерә алырсыңмы?

Равил МОСТАФИН

КАЗАЛЫП КИТ!

Мансур бер эчә башласа, хәтта өендәге барлык әйберләрне дә сатып эчеп бетермичә тукталмый икән. Инде өе дә шәп-шәрә калып, акча табылмагач, хатынының соңгы сумнарын-тиеннәрен сорап ялына башлый:

– Хатын, зинһар өчен, башым бик авырта бит, бер йөз граммлык кына булса да тап инде...

Хатыны:

– Бер тиенем дә юк! Казалып кит! – дип, ирен куып чыгарып җибәрә.

Мансур икенче көнне генә кайтып керә. Керәкерешкә:

– Хатын! Кичә суйган казларның берсе кайда ул?

Хатынының күзе чәй тәлинкәседәй зурая.

"Гаепсез" Мансур үзенең гамәленә шундук аклanып куя:

– Ник, үзең әйттең бит "каз алып кит" дип...

ӘХТӘМ АБЫЙ ШӘҺӘРГӘ БАРГАН...

Мамадыш, Чистай якларына барып, шәһәр кибетләрен күреп кайту малай-шалайлар хыялы гына түгел иде. Инде яше иллегә җиткән кеше өчен дә бик хаҗәт нәрсә иде ул. Чистайга барасы булса, Берсут пристаненә кадәр унсигез чакрым араны җәяүләп атлыйсың: ни атлы, ни машиналы кеше очрасын?!

Су трамваена утырып, Чистайга да килеп җитәсең...

Кырык яшьләрендәге Әхтәм абый да Чистайга кадәр үзе генә барган. Су трамваеннан төшкән дә, кибеткә йөгергән. Чиратсыз-нисез кереп, бер марҗа алдына килеп тә баскан. Әхтәм абый, ашыгуы сәбәпле, марҗаның аягына китереп басканын да сизмәгән.

"Убила!" – дигән тавыш сискәндереп җибәргәч, Әхтәм абый әлеге марҗадан:

– Прости, туткә! – дип, чын күңелдән гафу үтенгән.

Марҗа апа давыл куптарган:

– На ногу наступает, ещё обзывается! Милиция! Милиция!!!

Әхтәм абзый, шул көннән бирле шәһәр күргәнем юк, дип зарланып йөри ди хәзер...

ИРТӘ ҮЛДЕҢ, ӘТИ...

1990 нчы еллар. Чаллы икмәк комбинатында эшләп йөргән чор. Шул елларда, бик җор, кызларда гына була торган Чулпан исемле егет бар иде. Шул егет беренче хезмәт хакын Чаллының ГЭС бистәсенең уртасында ук урнашкан иске зиратта "юарга" уйлый.

Бер ярты, балык консервасы ала да уйлаган урынына юнәлә. Яхшы гына сыйлангач, башына килеп, җыр да сузып җибәрә.

Якыннан гына үтеп баручы милиционер, бу хәлгә аптырап, зират эченә керә. Зират җырчысы тәртип сакчысын күреп югалып калмый. Инде борынгылыгыннан иңеп, чокыраеп беткән бер кабер иңкүлеген кочаклап:

– Әй, әткәй, иртә үлдең шул, иртә үлдең! Бергәбергә озаклап яши дә алмадык, – дип, күз яшьләрен агыза икән.


Милиционер да, бу тамашаны күреп, шаярту катыш усал тел белән:

– Тор, егет, тор! Мине күргәч кенә, моннан берничә йөз ел элек үлгән "әтиең" өчен елап ятма монда! – дип, тәмам исерүе җиткән Чулпанны зират эченнән тиешле урынга – айныткычка ук озатып куйган ди...

Илдар НӘФИЕВ



Максим СМАГИН



Михаил ЛАРИЧЕВ





• • •

Житди мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен тормыш иптәше эзлим, аның өчен булачак гаилә, балалар һәм ире барсыннан да өстен, хәтта смартфоныннан да әһәмиятлерәк булырга тиеш...

• • •

Ашаганда мин ишетмим дә эндәшмим дә, дигән әйтем бар иде элек, ә хәзер бу сәяси караш, фикер.

• • •

Бездә, бик эссе булганлыктан, һава торышы бик кискен үзгәрәчәген белдереп, кисәтү ясадылар. Врачлар сәгать 10 нан 16 га хәтле ,урамга чыкмаска куштылар һәм иртән иртүк күбрәк эчәргә тәкъдим иттеләр. Күрше белән ике атнага якын эчтек. Эсселек беренче көннәрне, чыннан да, җиңелрәк кичерелде, аннан соң эшләр хөртиләнде һәм врач чакыртмый булмады. Ул безгә тимер эчәргә тәкъдим ясады. Без күршенең тимер гаражын эчеп бетердек, искиткеч рәхәт булып алды. Медиклар юкка иртән күбрәк эчәргә кушмыйлар икән шул!

• • •

– Һәр кич, яңалыклар тыңлаганнан соң, мин, гадәттәгечә, куркыныч фильмнар карап алам, юкса, тынычланып, йокыга һич китә алмыйм.

• • •

Бездә хезмәт хакы тагын да азрак булсын өчен, һәрвакыт аңа акчаны аз-азлап өсти торалар.

• • •

Кайчандыр безгә: "Күп белсәң – тиз картаерсың!" – диләр иде. Инстаграмчылар һәм тиктокерларга карыйм... болар мәңге яшиячәкләр!

• • •

Таныш булмаган номердан шалтыратсалар, беркайчан да трубканы алмагыз! Алар эш буенча шалтыратырга мөмкиннәр.

• • •

Ришвәт өчен җәзага тартылган түрәләр ирекләреннән мәхрүм ителмиләр, бары тик яңа эшкә күчү алдыннан ялга чыгып алалар.



ИНВАЛИД КҮПЕР БӘЛАСЕ

Кадерле "Чаян"! Борынгы бер акыллы әйтем бар: "Акыллы начар юлдан йөрми". Нәкъ безнең Зур Афанас авылы кешеләре турында инде бу! Эш менә нәрсәдә: кибеткә бару өчен безгә җимерек күпер аша йөрергә туры килә. Бөтенләй җимерелмәвенә аны мондагы Кулибиннар гына коткарып тора – иске машина тәгәрмәчләренең покрышкалары, ватык-китек кирпечләр һәм төрле баулар. Мондый "күпер"дән чыгу бәхетенә ирешү зур тапкырлык, зирәклек, саклык сорый. Әлеге сәнгатькә – бару-кайту-чыгу осталыгына хәтта пенсионерлар да ирештеләр. Юкса ризык-фәләнгә йөрү арасы ике чакрымга җыелыр иде.

Җирле хакимият бу проблеманы белеп торса да, ремонт ясарлык акча табу ысулына салкынлык белән карыймы, әллә киләчәктә яңа юл салыначагына өмет баглыймы? Әмма ул перспектива гына – аңа хәтле имгәнеп бетүебез көн кебек ачык булып чыга түгелме соң?

Түбән Кама районы

Зур Афанас авылы халкы

ЮЛ ТОТРЫКЛЫЛЫГЫ

Хөрмәтле редакция! Исегездә булса, бер билгеле фильм персонажы дөньяда тотрыклылык юк, дип зарлана иде. Ә менә Кукмара районының Мамашир авылы кешеләре бу фикер белән риза түгел. Төбәк аша узып, Киров трассасына чыга торган бердәнбер юл озак еллар буе тотрыклы рәвештә начар хәлдә булып кала. "Үрнәк" колхозы таркалганнан соң, аның бер тапкыр да ремонт күргәне юк. Дөрес, 2015 елда күпсанлы зарлардан соң эшчеләр килеп... юлның исән катлавын кисеп алганнар һәм аның урынына кызыл балчык салып киткәннәр. Чокырлар булмагач, зарланырга да урын юк, янәсе.

Җәен юлдан каршы машиналарны һәм җәяүлеләрне күрмәслек булып тузан күтәрелә. Язын һәм көзен үтмәслек сазлык,ә кыш көне юлдан читкә шуып төшүең дә бик мөмкин. Ләкин монда яшәүче халык өметләрен өзми һәм төрле урыннарга язудан туктамый. Бу турыда шаяртып та куйгалыйлар – сикәлтәле юлдан барган арада бөерләрдәге ташлар коелып бетә, имеш..

Р. РАМИЛЕВ

КУКМАРА районы



ИГЪТИБАР, КОНКУРС!

Кадерле дуслар! Туган тел һәм халыклар бердәмлеге елында "Чаян" журналы редакциясе "Чаянча чагу" дип исемләнгән юмористик хикәяләр конкурсы игълан итә.

1 июльдән 2021 елның ахырына кадәр сез редакциягә үзегезнең шаян хикәяләрегезне җибәрәсез. Без, үз чиратыбызда, аларның иң шәпләрен сайлап алабыз, журналда бастырабыз һәм авторларны акчалата призлар белән бүләклибез.


Ә хәзер игътибар! Үсеп торучы инфляция, биржа курсларының үзгәрүчәнлеген һәм азык-төлеккә бәяләрнең артуын истә тотып, призларның күләмен арттырырга карар кылынды. Җиңүчеләр өчен бүләкләр:

беренче урын өчен – 30000 сум;
икенче урын өчен – 20000 сум;
өченче урын өчен – 10000 сум.

Үзегезнең әсәрләрегезне редакциягә җибәргәнче chayan.ru.сайтында конкурсның шартлары белән танышыгыз.

Хикәяләрегезне көтеп калабыз! Конкурста уңышлар сезгә!

Нурислам ХӘСӘНОВның тууына – 80 ел



Теләче районының Шәтке авылында туган, югары белем алып, күп еллар Казан Моторлар төзү заводында эшләп тормыш тәҗрибәсе туплаган Нурислам – бүген ике дистәләп китап авторы. Язучы Барлас Камалов әйткәнчә, авылның һәм шәһәрнең кан тамырлары тибешен нечкәләп тоючы кешенең кырыс чынбарлыктан бөртекләп җыйган мәгълүмат сабагы, гыйбрәтле хис вә тойгылары аның җан әрҗәсенә генә сыймас дәрәҗәгә җиткән һәм ул аларны шигырь, нәсер итеп, парча, хикәя, повесть, роман итеп милләттәшләренә, ватандашларына сөйләргә карар кылган.

ЮЛДАШ

"Тәкъдир"еңдә язгансың
"Язмыш җиле"н уйнатып.
"Күрәзәче" булмасаң да,
"Җан авазы"ң ап-ачык.

Дүрт томлык тәҗрибәң бар,
Утлар-сулар кичкәнсең.
Хакыйкатьне маяк иттең –
Шәп язучы икәнсең!

Алмаз ХӘМЗИН

КЕРЕМЕ...

Исәнме, дус, исәнме!
Алмагачлар үсәме?
– Шәп, шәп, туган, шәп бакча,
Бакчада икән акча.

– Эштән син киләсеңме?
– Эшләмим, беләсеңме?
Бакчага көч күп китә.
Кереме ярый инде,
"Волга" алырга җитә.

• • •

Телең белән ялама син, ялагай,
Мин – тимер,
Тешең үтсә, кимер.

• • •

Солидный егет дисеннәр,
Балагымны тар итәм.
Парлашып бергә үтәбез,
Тар итәкне яр итәм.

• • •

Бер кигәндә кия итәк,
Бер кигәндә – тар балак.
Ай-һай, чибәр килешләре –
Нәкъ чуп-чуар ябалак.

"ПАРТИЙНЫЙ" ҮГЕЗ

– Наис Хаевич! Нигә сөтең кими? Кайчан арттырасың?

– Сыерлар бозаулый башлагач инде, Сәлим Хаҗиевич.

– Син теге юлы да шулай дидең. Сыерларың елга ничә тапкыр бозаулый соң синең?

– Бер тапкыр.

– Үгезең юкмыни соң синең?

– Барын бар да...

– Булгач?

– Үгез "партийный" булып чыкты бит, Сәлим Хаҗиевич. Демократлар ягына авышкач, үз сыерлары ягына әйләнеп тә карамый башлады.

– Башын бетер син аның. Беткән партия үгезләрен тотар заман түгел хәзер. Үзеңнең дә симерүең җиткән, кара аны...

КӨРӘШЧЕЛӘР КИРӘК!

– Туктагыз әле, сез монда Инеш авыл Советы эшен яхшы да, яхшы дип мактап утырмагыз. Ярар, менә син, Ленар, әйт. Авылыңда музей бармы?

– Бар, Шаһ Назарович, бар...

– Ярар, монысы булсын да, ди. Чишмә авылында сөт җыялармы?

– Җыялар, Шаһ Назарович, җыялар. Хәдичә апа җыя.

– Монысы да ярар. Ә менә Ташлыяр авылында фермаң юк. Халык эш белән тәэмин ителмәгән. Эшләрең болай барса, авылың таралачак синең. Юк, син булдырма. Бу берме? Бер. Ә көрәшчеләрең кая? Син бит бер генә көрәшче дә тәрбияли алмагансың. Эшне көрәшчеләрдән башларга кирәк. Авыл данын көрәшчеләр күтәрә! Ичмасам, таралган авыл музеенда көрәшчеләр экспонатлары саклаңып калсын...

ОЗЫНГА КЫЗЫКМАГЫЗ!

– Ләис! Нигә бу басуыңда бодаең үсмәгән синең? Әнә күрше совхозныкына кара, нинди озын, билдән бит.

– Озын әйбәт түгел ул, Хәким Хөрмәтович, әйбәт түгел. Озынга бер дә кызыкмагыз сез.

– Ник?

– Озын, ни, шәп түгел бит ул, озынны бер дә мактамыйлар аны. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам, әйбәт түгел ул озын.

– Тукта әле, ник әйбәт түгел озын?

– Ни бит, Хәким Хөрмәтович, озын... озын сыек була бит ул, утырып тормый.

– Ну, шуннан?

– Җил ега бит аны.

– Ярар, син кыска кеше. Кысканы макта. Ә менә Бәдри Идрисович озын, аңа карап җил екмый бит аны.

– Әйтәм бит, Хәким Хөрмәтович, озынга кызыкмагыз Сез, шәп түгел ул озын... "Чылануы" җитсә, Бәдри Идрисович та егыла.





Дамир МОРТАЗИН



Житәкчең белән яхшы мөнәсәбәт урнаштыру бик җайлы нәрсә түгел, диләр. Әгәр дә кешенең башы үз урынында икән, ягъни әйбәт эшли дип әйтик (мәкинә тутырылган түгел), ул чагында теләсә нинди җитәкче белән уртак тел табарга мөмкин.

Менә, әйтик, безнең оешмадагы хезмәткәр Рәүф. Ул директорның үзенә салкын карашын күптән тоеп йөри – ә бит, чыннан да, сәбәбе бар түгелме соң? Рәүф тегеләй итеп карады, болай – бер алдына чыга, бер артына дигәндәй – тегесе колагына да элми.

Бервакыт сату бүлегенә керер алдыннан, ул тын алуын шулкадәр кысып торды, хәтта күгәреп катты. Кергәч, тыела алмыйча көлә-көлә урындыкка ауды.

– Менә әле генә шеф бер мәзәк сөйләде, – дип көчкә көлүеннән арынып башлады Рәүф сүзен, – чак кына шартламый калдым!

Һәм күңеленә килгән бер мәзәген сөйләргә кереште. Инде тәмамлап, көлә-көлә чыгып киткәч, хезмәттәшләре бер-берсенә карашып алдылар.

– Кара инде, Гали Галиевич моңа үзе мәзәк сөйли, ә башкаларга акырабакыра, аяк тибеп сүгә...

Иртән Рәүф, алданрак килеп, проходной янында каравылчы каршына басты да, блокнотына ниләрдер язарга тотынды. Моны күргән коллегалары көне буе пышылдаштылар.

– Дустына безнең арттан күзәтеп торырга булыша... Кем соңга калган шуларны яза...

Төш вакытында Рәүф янына бүлек мөдире Мәрданов килеп утырды. Ял көннәрендә үзенең бакчасына кунакка чакырган.

– Гафу ит, килә алмыйм, – дип бик тәкәббер генә итеп җавап биргән аңа Рәүф, һәм аңлатмалы карашын күккә төбәгән. – Шефка вәгъдә иткән идем... Үзең аңла... Якташыма каршы килә алмыйм...

Берчак ул эшкә кызарган күзләрен уа-уа килде, үзеннән тәмле шәрәб исе аңкый.

– Кичә Галиевич белән яхшы гына утырган идек, – дип тыйнаклык күрсәткәндәй кыланды да өстәп куйды, – яңа эш машинасын юдык... Башның чатнавына түзәрлек түгел!

Хезмәттәшләре хәлен аңлап, җыештыручы Саимә апаны сыра артыннан җибәрделәр.

Әкренләп Рәүф бик кәттә кешегә әверелә башлады. Аны берсен-берсе уздыра-уздыра төрле кичәләргә, туган көннәргә чакыралар, үзләре өчен Гали Галиевичкә сүз катуны үтенеп сорыйлар. Хәтта аны башкалар каршында эшли белмәгән өчен директор сүккәндә дә, коллегалары, хәленә кергәндәй, бер-берсенә карашып куйгалаган булдылар.

– Бу аның любимчигы икәнен каплау өчен генә... Конспираторлар... – диештеләр.

Тиздән әлеге чыш-пышлар директорга барып ирешә. Ул аларны нихәтле генә кире какмасын, хезмәткәрләре арасындагы фикерләр ныгый гына барды, әйе, бу – оста кылану.

Тора-бара директорны барлыкка килгән мондый хәл туйдырды һәм Гали Галиевич бер киңәшмәдә, оптимизацияне сәбәп итеп, Рәүфне эшеннән азат итү турында фикер әйтте.

Секунды-минуты белән урынбасары Сәлимов аңа теләктәшлек белдерде.

Бик вакытлы тәкъдим! Бу эш урыны безгә бөтенләй кирәк түгел. Бер уйласаң, Рәүф Рәисович югарырак кәнәфигә лаек. Мин аны директор киңәшчесе итеп билгеләргә фикер кертәм!

– Мин бернинди дә киңәшчегә мохтаҗ түгел! – дип кабынып куйды директор. – Берәүне дә беркайда да билгеләргә кыстамыйм...

Барысы да аның хәленә кергәндәй елмайдылар.

Шулай да директор Рәүфне башка оешмага тәкъдим итүне кирәк дип тапты, бик тә җаваплы урынга. Гомуми сорау һәм җаваплар буенча урынбасарлыкка. Рәүфнең китүенә теләктәшлек белдереп, барысы да башларын селкеп алдылар...

Ә югыйсә җитәкчелек белән эшне җайлап-майлап булмый диган булалар!

Шәраф МӨДӘРРИС

ТӘНКЫЙТЬ СӨЮЧЕ

Торып басты "хуҗа кеше":
– Шулай, шулай, туганнар!
Дөрес барлык тәнкыйтегез,
Очсын өстән тузаннар!
Иптәш Хаков хакны әйтте,
Рәхмәт сезгә, дусларым!
Җаным бирәм үтәү өчен
Коллективның кушканын!
Каты әйтте иптәш Хаков,
Ләкин нигә рәнҗисе...
Ярдәм итәр минем эштә
Якын дуслар тәнкыйте!
Үтте ун көн. Бәйрәм җитә,
Шатлык нуры күзләрдә.
Кирәк рәхмәт белдерергә
Приказ белән күпләргә.
Исемлектә — алдынгылар,
Карый "хуҗа" бит башын.
– Кем бу? Хаков? Сабыр итсен
Кыек йөртә кепкасын...
Әйткән сүз инде – аткан ук,
Хәрәкәттә – бәрәкәт.
Хаков төште исемлектән,
"Хуҗа кеше" канәгать.



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 9 (1910) сентябрь 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.

Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 03.09.2021 ел.
Тираж – 3344 Заказ Е-2963

**Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.**

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

16+

Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!

ЯЗУЧЫ АДЛЕР . . .
ТЕЛЕВИЗОРДА һӘМ МОНИТОРДА
. . . БИКТАҺИРОВ
“КАРА ДА ГЫНАЙ . . .”
“. . . ЯНА ЙӨРӘГЕМ?”
10000 м²
“. . . ЧӘЧӘК АТА ИЛЕМ”
“. . . ТАУДА”
ЖЫРЧЫ ИЛСУР САФИН
“СУТЫЙ”
“КҮМЕЛГӘЧ ГӨЛГӘ . . .”
СӘНГАТЬ ТӨРЕ(-1)
КАРДӘШ
ФАТИХ КӘРИМ ШИГЫРЕ
СЫРЫША ТОРГАН ҮЛӘН
ЯПОНИЯДӘ “БОЛАННАР ШӘҺӘРЕ”
ОЯТ
. . . АХУНОВ
“. . . КИЛМИСЕҢ, БЕР ГЕНӘМ?”
. . .-БИРЕ
ХАЛЫК ЖЫРЫ
. . . АЙМӘТОВ
ФИН ЯЗУЧЫСЫ МАРТТИ . . .
ШАГЫЙРЬ . . . РӘХМӘТ
“ӘЙТЕР СҮЗЕМ (-1). . .”
ЖЫРЧЫ ИДЕАЛ . . .
“ТӘНДӘ ЖАНЫМ ТОРСА . . .”
“. . . БУЛАСЫМ КИЛМИ“
АЮНЫҢ ФАТИРЫ
“КҮҢЕЛЕМДӘ . . . — САРЫ САГЫШ”
БИЕК-ЛЕК
“. . .(-2) ЯКЛАРЫНА КАРЫЙМ“
“ҮСЕП УТЫРА БЕР КАРТ . . .” (ЖӘЛИЛ)
. . . ҮЛӘНЕ
“ИРЕННӘРЕ . . . ГЫНА”
“БӨДРӘ . . .”
ШАГЫЙРЬ, КОМПОЗИТОР ЛӘБИБ . . .

ЖЫРЧЫ . . . ЯКУПОВ

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Кем ул сатирик?

2. Иң пошынмый торган хайван?

3. Әкиятләр ни өчен уйлап чыгарылган?

4. Элек белән хәзернең аермасы?

5. Ни өчен банан чөгендер һәм бәрәңгедән очсызрак?

6. Нәселлекнең начарлыгы нәрсәне аңлата?

7. Безнең пирамидаларның мисырныкыннан аермасы нәрсәдә?

ҖАВАПЛАР

1. Ипотека алган мәзәкче. 2. Атны җигәләр, ә ул кешни генә. 3. Ичмасам, кайда булса да явызлыкны җиңү өчен. 4. Элек: “Менә үсеп җитим әле”. Хәзер: “Менә акча булгач”. 5. Бәрәңге белән чөгендерне Рәсәй буйлап йөртәләр, бананны – диңгездән корабка төяп кенә киләләр. Ә диңгездә гаишниклар юк. 6. Васыятьнамәдән сызып калдыруны. 7. Мисырларныкы чорлар буе тора, ә безнекеләр бер елга да чыдамый.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.


Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 8 нче санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«ЭХ, ДУСКАЕМ, КИЛ ӘЛЕ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Р. САФИН (Балык бистәсе, Полянка ав.),
Л. СӘЕТГАЛИНА (Актаныш),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Апастан **Зәйнәп ЯРУЛЛИНА!**







Ринат АБЗАЛОВ

Виктор ФЁДОРОВ





Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Николай ВОРОНЦОВ

